Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

6 апрель, 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Ленино-Кокушкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 - 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге уставы, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлегендә җәмәгатьчелек фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә (2017 елның 12 декабрендәге 47 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 59 номерлы, 2019 елның 23 сентябрендәге 103 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 58, 2023 елның 31 мартындагы 66 номерлы үзгәрешләре белән) нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең проектны гавами тыңлаулар уздыру юлы белән фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Ленино-Кокушкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә (алга таба - җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия);

2.2. гавами тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2023 елның 10 маенда 10.00 сәгатьтә Ленино-Кокушкино яшьләр үзәгенең тамаша залында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Ленино-Кокушкино авылы, Үзәк ур., 7;

2.3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы, түбәндәге адрес буенча: 422780, Татарстан Республикасы, Питрәч

районы, Ленино-Кокушкино ав., Үзәк ур., 7 (дүшәмбе-җомга 8-00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр һәм 13.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр) күрсәтелгән, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертелергә мөмкин;

2.4. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектына тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү срогы - 2023 елның 10 апреленнән 2023 елның 5 маена кадәр;

2.5. Ленино-Кокушкино авыл җирлеге халкына җиткерү максатыннан 2023 елның 18 апрелендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектының демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен өч көнгә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге авыл мәдәният йорты бинасында, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Ленино-Кокушкино ур., Үзәк ур., 57Б/1 адресы буенча (дүшәмбе-җомга 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр һәм 13.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр) оештырырга.

3. Ленино-Кокушкино авыл җирлегендә яшәүчеләр Интернет челтәрендә (www.pestreci.tatarstan.ru) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты белән «Сельские поселения – Ленино-Кокушкинское сельское поселение» бүлегендә танышырга мөмкин.

4. Комиссиягә:

4.1. «Вперед» («Алга») район газетасында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны бастырырга;

4.2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә билгеләнгән тәртип һәм әлеге карарның билгеле бер сроклары нигезендә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

4.3. гавами тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне, шулай ук эшкәртелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектны җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын тәкъдим итәргә;

4.4. җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге мәгълүмат стендларында һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р. Сәйфетдинов